РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ КИЯТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЫЯТ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«23» ноябрь 2020 ел № 1-6

ТР Буа муниципаль районы Кыят авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы һәм муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кыят авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Буа муниципаль районы Кыят авыл җирлеге Советының 2019 елның 26 февралендәге 65-1 номерлы карары белән расланган (12.02.2020 ел, № 87-1, 20.10.2020ел, № 3-4 карар редакциясендә), Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кыят авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (алга таба текст буенча – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

16 бүлек:

16.3 пунктының 16 абзацын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

« Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, күрсәтелгән муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтын төшереп калдыру максатларында әлеге җирле үзидарә органының сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфаны биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмыйлар.».

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Буа муниципаль районы Кыят
авыл җирлеге башлыгы Е.С. Корунова